# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№6 (730) 24 март 2021 ел (1442, Шәгъбан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ГЫЙЛЕМ МӘҖЛЕСЛӘРЕ



Республикабызда дөньяви уку йортлары белән беррәттән, дини мәдрәсәләр, Россия Ислам университеты, Болгар ислам Академиясе эшли. “Ак мәчет” мәдрәсәсе Чаллыда урнашкан, ул республикабызның дини мәгариф үсешенең бер мисалы булып тора. 13 мартта «Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте» дигән алтынчы халыкара конференция дә үз югарылыгында оештырылган иде, ул оффлайн һәм онлайн форматта дин галимнәре, фән докторлары, профессорлар катнашында узды. Чара дога белән һәм мәдрәсә директоры, «Ак мәчет» имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиевның сәламләве, хәер-фатыйхасы белән башланып китте. Россия ислам институты ректоры Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин дә котлау сүзләрен ирештерде. Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин сәламләү сүзләре җиткергәннән соң: «Бүген дә гыйлем мәҗлесендә без. Гыйлем булганда, дин дә, милләт тә була», - дигән фикерен ирештерде. Иордания профессоры Шәйх Абд әр-Раззак Абд әр-Рахман әс-Сагди, академик М.Ф.Зәкиев, профессор А.Ю.Хәбетдинов, Әзәрбайҗан профессоры Г.А.Сайылов, рәссам-каллиграф Н.Ф.Исмәгыйлев (Нәҗип Нәккаш), Казахстан профессоры А.К.Дуйсенбаев, филология фәннәре докторы Ә.М.Закирҗанов чыгышларында җәмгыятьтәге мөһим проблемаларга кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде. Соңыннан секцияләргә бүленеп эшләгән сәгатьләрдә дә галимнәр һәм мәдрәсә мөгалимнәре тарафыннан тирән мәгънәле, безне урап алган тирәлек һәм дин мәсьәләләренә яңа күзлектән карарга мөмкинлек бирүче чыгышлар булды. Яшерен-батырын түгел, бүгенге көндә дин һәм дин эшлекләләре турында безнең күзаллауларыбыз әлегә бик тар һәм гаять чикләнгән. Ни кызганыч, хәрәтләрнең дә, мәдрәсәләрнең дә эшчәнлеген менә шул үзебез тудырган күзаллауда гына гоманлыйбыз. Никах, Коръән ашлары, исем куйдырулар, намаз, дин сабаклары... Ә бит мондый конференцияләрне генә мисал итеп алсак та, аларда күренекле галимнәрнең катнашуы күп нәрсә турында сөйли. Биредә ясалган чыгышларның электрон варианты «Россия электрон китапханәсе»нә кертелә, алар җыентык итеп эшләп бастырыла.



Мәчетнең имам-хатыйбы һәм мәдрәсәнең директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев белән бер әңгәмәдә аның: «Кая барсам да галимнәр белән аралашам мин. Тарих институтына, академиягә еш барам. Чөнки дин ул - тәһарәт, намаз белән генә чикләнми. Ул бөтен яшәешне, бөтен элитаны үз эченә ала, бергә тупланып эшләмәсәң, милләтнең киләчәге юк аның. «Милләт, милләт» дип кычкырып йөрүче күп, шул кешегә берәр эш кушсаң, шунда ук «түләве күпме» дип сорый...Түләүле хезмәт белән милләтне торгызып булмый!» - дигәнен искә төшерәм. Дөньяга киң караш белән багу, үз казанында гына кайнамыйча, киңлеккә омтылу, гыйлемнең һәм камиллекнең чиге юклыкны аңлау менә шушындый колачлы чаралар уздырырга этәрәдер дә, мөгаен. Югары уку йортлары, аеруча Чаллы дәүләт педагогия институты белән кулга кул тотынып эшләүләре инде бик күптәннән килә. Төрле чаралар уздырганда мәдрәсәдә татар теле, татар халкы тарихы укыткан, филология фәннәре кандидаты Ринал Хаҗиевның һәрчак зур таяныч булуын искәртү урынлы булыр.

Конференциядә катнашканнарның берсе дә әлеге чарадан буш һәм битараф күңел белән кайтып китмәгәндер дип ышанасы килә. Уйланып киткәндер. Нинди генә өлкәдә, нинди генә ачышлар ясалмасын, кайсы чорда, кайсы җәмгыятьтә генә булмасын, аларның чын хуҗасы - Берәү генә, безнең дә таяныр ноктабыз - Берәү генә...

***

Гыйлем мәҗлесенең икенчесе 15 март көнне уздырылды. Чаллы мөхтәсибәте шәһәрнең мәчет имамнары һәм Рәсәй Ислам институтын, Болгар Ислам академиясен тәмамлаучылар катнашында “XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы татар дин галимнәре мирасы” дип аталган фәнни-гамәли конференция үткәрде. Чарада М.Бубый, Г.Курсави, Г.Баруди, Р.Фәхреддин кебек шәхесләргә һәм татар дин галимнәренең хезмәтләренә кагылышлы темаларга чыгышлар ясалды. Конференция Коръән аятьләре укылганнан соң Чаллы имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллинның нәсыйхәтләре белән башланып китте. Инсаф хәзрәт Сәүбанов, Илдар хәзрәт Зияров, Рамазан хәзрәт Идрисов, Мөхәммәд хәзрәт Мөхәммәтов, Гөлфия Насыйбуллина, Раил Фәйзрахманов Сөмбелә Фәхретдинованың эчтәлекле чыгышлары тыңланылды.

**Айгөл Әхмәтгалиева**

## ТИЗДӘН - РАМАЗАН АЕ!



22 нче мартта нәзарәттә Голәмәләр һәм Казыйлар шурасының киңәйтелгән утырышы үтте. Хәзрәтләр рамазан ае башлану һәм тәмамлану вакытына, тәравих намазында укыла торган рәкәгатьләр санына, фидия һәм фитр сәдакаларына кагылышлы дини сорауларны тикшерделәр. Көн тәртибендә быел — 2021 елда якынлашып килүче Рамазан-шәриф аен үткәрү белән бәйле мәсьәләләр каралды. Уразаның башлану һәм тәмамлану көннәре билгеләнде: 13 апрельдә — уразаның беренче көне, 12 майда — уразаның соңгы көне. 12 апрельдә — беренче тәравих намазы, 13 майда — Ураза бәйрәме.

## ЯҢА КИТАПЛАР




“Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгендә тирән эчтәлекле, һәркемгә таяныч булырлык китаплар даими басылып тора. Күптән түгел дөнья күргән “Һәфтияк шәриф” тә (Казан басмасы) - шундыйлардан. Башка елларда басылганнарыннан аермалы буларак, бу китап Коръән сүрәләре һәм аятьләрнең согуди язылышта төсле итеп бирелүе белән үзенчәлекле. Биредә әйтелешкә аңлатма, аятьләргә бирелгән тәфсирләр камилләштерелеп, транскрипция тәҗвид кагыйдәләренә туры китерелеп, шулай ук төсле вариантта тәкъдим ителә. Китапны типографиядән дә, “Ислам нуры” кибетеннән дә алырга мөмкин.

Адресыбыз: Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк урам, 72 нче йорт.

# УРАЗАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ

Бөек Раббыбыз әлеге аятьтә әйткән: «...**Аллаһы сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми**...». («Әл-Бәкара», 2:185)

Ураза кешегә ни бирә?

Мөселман иртәдән кичкә кадәр ашамыйча-эчмичә, җенси теләкләрен тыеп, уразасын фарыз шартларга туры килерлек итеп тота ала. Ләкин уразадан көтелгән файдага ирешмәве дә мөмкин. Беренче чиратта шуны әйтергә кирәк: уразаны Аллаһы Тәгалә әмер иткәнлектән, Аның ризалыгы өчен тотабыз. Шул ук вакытта, без әлеге әмерне үтәгәндә ниндидер файдага да ирешәбез. Чөнки, Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, аларның барысында да безнең өчен дөньяви вә рухый файда бар. Югыйсә, безнең аларны кылып-кылмавыбыздан Аллаһы бернинди файда да, зыян да күрми. Гомумән, безнең ач торуыбыз Аллаһыга кирәкме? Аллаһы галәмдәге бер нәрсәгә дә, бер мәхлукка да мохтаҗ түгел.

Аллаһы Тәгалә Үзенең әмерләрен колларына золым, авырлык һәм кыенлык теләп бирмәгән: «...**Аллаһы бәндәләренең һичберсенә золым теләми**». («Әлү Гыймран», 3:108)

Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, алар барысы да, чыннан да, безнең матди вә рухый ягыбызны карау өчен әмер ителгән. Әмма без бары Аллаһы кушканлыктан һәм Аның ризалыгын алыр өчен генә гыйбадәт кылабыз. Мондый зур файдалы мөмкинлекне әмер иткәне өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсәк иде.

Аллаһы ризалыгы өчен тоткан уразабыз матди вә рухый файдага ирешә алсын өчен, нәрсәгә игътибар итәргә кирәк соң? Бу хакта исламның бөек галиме вә күренекле фикер иясе имам Газзали «Ихйа-у Улуми-д Дин» исемле әсәрендә язып калдырган. Ислам динен яхшы белгән һәм Аллаһы кушканча яшәргә омтылган мөселманның уразасы түбәндәгечә булырга тиеш:

Уразалы кеше үзенең күзләрен һәртөрле яманлыклардан сакларга бурычлы. Күз зинасыннан саклану лазем. Башкаларның малына, намусына яман күз белән карау ярамый. Кемнеңдер малына кызыгып карау тыела. Боларның барысын да Аллаһы Тәгалә бирә бит. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам үзенең бер хәдисендә болай дигән: «Күзләрен хәрам белән тутырган кешене Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә аның күзләрен ут белән тутырыр».

Колакларын һәртөрле яман сүзләрне ишетүдән сакларга тиеш. Ураза тотучы колакларын яман сүзләргә шаһит булудан сакларга тиеш. Моның өчен аңа яман сүзләр сөйләшүче кешеләр янында утырмаска кирәк. Ул берәр мәҗлестә динне мәсхәрәләү, сүгү һәм мыскыл итүгә шаһит булса, андагы кешеләрне бу хакта сүз катудан туктатырга яисә алар яныннан чыгып китәргә тиеш.

Телен һәртөрле ялган вә яман сүзләр сөйләүдән, ялган антлар бирүдән, буш сүзләрдән сакларга тиеш. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип боера: «...**Ялган сүздән сакланыгыз**». («Әл-Хәҗ», 22:30) «**Әй мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен генә сөйләгез**». («Әл-Әхзәб», 33:70)

Әбү Һурәйрәдән (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять ителә ки, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә (аның хаклыгына, котылгысызлыгына) ышанган кеше яхшы сүз сөйләсен яки эндәшмәсен!». (Бохари)

Мөселман кешесе барлык әгъзаларын да яман гадәтләрдән сакларга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Бер кеше башкаларның яман сүзләрен вә гамәлләрен кире какмаса, «Ураза тотам» дип ашамый-эчмичә һәм җенси теләкләрен тыеп торуыннан бернинди дә файда булмас. Бары фарызы гына үтәлгән булыр». (Бохари)

Ифтар вакытында күп ашарга ярамый. Кояш батканчы буш торган ашказанын кисәктән шыплап тутырып куюсәламәтлеккә файда бирмәс. Моны медицина фәне дә раслый. Асылда, ахшамга азан әйтелгәч, берничә хөрмә яки зәйтүн җимеше, яисә, бер стакан су белән авыз ачарга кирәк. Аннары – ахшам намазы укыла. Намаздан соң ифтар ризыгы белән авыз ителә. Ләкин бик күп ашап куюдан сакланырга кирәк.

Ураза тотучы ифтар кылганда (авыз ачканда) курку белән өмет арасында булырга тиеш. «Мин бүген ураза тоттым, әмма ул кабул ителмәде» дип, өметсезлеккә, куркуга бирелергә ярамый. Мөселман кешесе беркайчан да Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзмәс: «...**Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһы гөнаһларны ярлыкаучыдыр, Ул (Аллаһы) ярлыкаучы вә рәхимле**». («Әз-Зүмәр», 39:53) Ләкин: «Аллаһы ничек тә гафу итәр әле», «Уразам кабул ителгәндер» дип, нык ышаныч белдерергә дә кирәкми. Чөнки, Аллаһы тели икән – гафу итә, теләми икән – гафу итми. Берәү дә Аллаһыны гафу иттерергә мәҗбүрили алмый. Шуңа күрә, ураза тотучы өмет белән курку арасында булырга тиеш. Уразаны Аллаһы ризалыгы өчен тотарга тырышу лазем. «Кабул булмаса нишләрмен», дип курку тиешле. Шул ук вакытта, уразаң кабул булсын өчен Аллаһыга дога кылырга кирәк.

Мөхтәрәм җәмәгать! Рамазан-шәриф – Аллаһының китабы Коръәни-Кәрим иңгән ай, ягъни Коръәнне уку, өйрәнү, аның аятьләре, сүрәләре турында уйлау, фикер йөртү һәм, әлбәттә, Коръән буенча яшәү ае. Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә: «**Рамазан ае – кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр**». («Әл-Бәкара», 2:185)

Коръән укуның фазыйләтләре турында сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам үзенең бер хәдисендә болай дигән: «Коръән укыгыз, чөнки Аллаһының китабыннан укылган һәрбер хәреф өчен ун савап биреләчәк, мин әлиф-ләм-мим бер хәреф дип әйтмим, чөнки аларның һәрберсе аерым хәреф, аларның барысы өчен дә унар савап биреләчәк». (Тирмизи)

Әбу Һурәйрә исемле сәхабә (Аллаһы аннан разый булса иде) риваять кылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәллам әйткән: «Әгәр бер кеше мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса – Кыямәт көнендә Аллаһы ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр бер кеше бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә – Аллаһы аның хәлен бу дөньяда да һәм ахирәттә дә җиңеләйтер. Бер кеше үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә Аллаһы аңа Үзенең ярдәмен дә ирештереп торыр. Гыйлем алу юлына баскан кешегә Аллаһы җәннәт юлын җиңеләйтер. Кешеләр Аллаһы йортына җыелып Аның Китабын укыганда мөселманнарның җаннарына тынычлык иңәр, алар бәрәкәтле булыр вә фәрештәләр алар өстендә канатларын җәеп торыр. Алар Аллаһы Тәгаләгә якын булыр». (Мөслим, Әбу Дауд, Тирмизи, Ибн Мәҗәһ)

Әгәр мөселман кешесе көндез ураза тотса, төннәрен Коръән укыса, Кыямәт көнендә аның ике яклаучысы булачак. Алар мөселманнарга Аллаһыдан ярлыкау һәм Җәһәннәм утыннан котылу сораячак. Шул ике яклаучының берсе – ураза, икенчесе – Коръән булыр. Хәдистә әйтелгән: «Ураза һәм Коръән Хисап көнендә Аллаһының колын яклаячак. Ураза әйтер: «Йә Раббым, көндез мин аны ризыксыз вә сусыз тилмерттем, шунлыктан мин аның өчен Синнән ярдәм сорыйм». Коръән әйтер: «Йә Раббым, мин аны төнге йокысыннан калдырдым, шуңа күрә аңа Үзеңнең рәхмәтеңне ирештерсәң иде». Аларның үтенечләре кабул ителәчәк». (Әхмәд ибне Хәнбәл, Мүснәд)

Ибн Габбас (Аллаһы аннан разый булса иде) риваять кылган: «Җәбраил галәйһиссәләм рамазан аеның һәр төнендә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм белән очрашып, аның белән бергә Коръән өйрәнгән». (Бохари, Мөслим)

Кадерле мөселманнар! Аллаһы Раббыбыз безгә дә Рамазан аеның төннәрендә уяу торып, Аллаһының Китабын укып, Аның бетмәс-төкәнмәс әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсә иде.

Рәсүл Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәллам икенче бер хәдисендә болай дигән: «Ике төрле кешедән генә көнләшергә ярый: беренчесе – Аллаһы Тәгалә Коръән байлыгы биреп, шуның белән көн-төн мәшгуль булучыдан; икенчесе – Аллаһы Тәгалә күп нигъмәтләр биреп, шул байлыгын изге юлда сарыф итүчедән». (Бохари, Мөслим)

Аллаһы Раббыбыз һәрбарчаларыбызга да Коръән буенча яшәп, ике дөньяда да бәхет-сәгадәткә ирешүчеләрдән булырга насыйп итсә иде.

*Үзәкләшкән дини оешма –*
*Татарстан Республикасы мөселманнары*
*Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге*

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Ураза тоткан кешенең йокысы - гыйбадәт, эндәшмәве - тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһасы гафу ителгән булыр

* Җәннәттә әр-Рәййан дигән бер ишек бар. Бу ишектән Кыямәт көнендә бары тик ураза тотучылар гына керәчәк. Аннан ураза тотучылардан башка берәү дә керә алмаячак

* Ураза тотуны дәвам ит, чөнки аңа тиң булырлык башка гамәл юк

* Ураза - ул кешене җәһәннәм утыннан саклый торган калкан

* Чыннан да, җәннәттә шундый бер йорт бар: эченнән тышы, тышыннан эче күренә. Аллаһы Тәгалә аны йомшак сөйләшкән, кешеләрне ризыкландырган, даими ураза тоткан һәм башка кешеләр йоклаганда төнлә гыйбадәт кылганнар өчен әзерләгән

* Әгәр дә кешеләр Рамазан аеның хикмәтен белсәләр, Рамазан аеның ел буе булуын теләрләр иде

* Сезгә бәрәкәтле Рамазан ае килде. Аллаһ Тәгалә сезгә ул айда рәхмәтен иңдерә, гөнаһларны гафу итә һәм догаларга җавап бирә. Аллаһ сезнең берберегез белән изгелек кылуда ярышуыгызга карый һәм фәрештәләр алдында сезнең белән мактана. Аллаһка үзегездән хәерле нәрсәне күрсәтегез. Дөреслектә, бәхетсез кеше ул бу айда Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм булган кеше

*ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ*

# “БУ АЙГА ИРЕШКӘННӘР УРАЗА ТОТСЫН!”

*13 апрельдә барлык мөселманнар өчен мәртәбәле Рамазан ае башлана. Уразаның асылы нидән гыйбарәт – шул хакта Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе **Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН** белән сөйләшәбез.*

**- Әлфәс хәзрәт, ураза тоту, рамазан ае хакында Коръәни Кәримдә ниләр әйтелә – сорауны шуннан башлыйк әле.**

- Ураза тоту ул – Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен, таң беленгәннән алып кояш батканга кадәр үзеңне бер тамчы ризыктан, судан һәм начар эшләрдән, начар гамәлләрдән саклау. Рамазан ае хакында Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең аятьләре бар. “Бәкара” сүрәсенең 183 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: “Әй, иман китерүчеләр, сездән алдагы өммәтләргә дә тиеш булган яки фарыз булган кебек, сезгә дә елның бер дәверендә ураза тоту фарыз ителде”. Ягъни, Аллаһы Тәгалә безгә әйтә: ураза тоту ул аерым бер мөселман өммәтенә генә бирелгән түгел, яки алдагы өммәтләр дә, алдагы китап әһелләре дә уразаларын тоттылар, әмма безнең ураза белән аларның уразаларының аермасы бар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә “Бәкара” сүрәсенең 185 нче аятендә раслап әйтә: “Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын”, - ди. Бу - Аллаһының әмере. Эшләр, мәшәкатьләр булу, эшнең авыр булуы – болар берсе дә уразаны тотмаска сәбәп була алмый. Әмма Аллаһы Тәгалә шунысын да билгели: кемдер авырып китте, кемдер сәфәр чыкты - алар уразаны тотмаска мөмкин

. Уразаны ничә көн калдырсалар, соңыннан, рамазан ае үткәч, шуны тотып бетереп, тәгаллән куярга тиешләр. Әлбәттә, икенче рамазан ае житкәнче калдырмаска, тотып бетерергә тиешләр. Кемнәр ураза тотмас: ул да булса бик зур картлык зәгыйфьлегенә ирешкәннәр һәм авырулары сәбәпле, аларга гел дару эчеп торырга, капкалап, ашап торырга кирәк булса, алар ураза тотмаслар. Әмма, мөмкинлекләре булса, фидия бирерләр. Бер көнне бер кешене ашату яки бер ай буена бер кешене ашату, я бер көн эчендә 30 кешене ашату кебек фидия бирерләр. Әгәр инде фидия бирергә дә мөмкинлекләре булмаса, шушы эшләрне эшләрлек мөмкинлекләре булмаса, ул вакытта аларның өсләреннән төшә. Менә шушыларны хәбәр итә Аллаһы Тәгалә рамазан ае хакында. Рамазан ае ул – 11 айның солтаны, Коръәни Кәрим иңдерелгән ай. Менә шуның белән рамазан аеның дәрәҗәсе күтәрелә.

**- Ураза - тән өчен генәме, әллә җанны да ураза тоттыру мөһимме?**

- Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисендә болай диелә: “Сез уразаны ялгыз ашказанына гына түгел, ә бөтен тәнегезгә тоттырыгыз”. Ягъни без үзебезнең тәнебезне начар гамәлләрдән, начар эшләрдән сакларга тиеш, уразаны без күзебезгә дә, колагыбызга да, телебезгә дә, аякларыбызга да, йөрәгебезгә дә һәм бөтен әгъзаларыбызга да тоттырырга тиешбез. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Ураза ул – калкан”, - ди. Сугышчы сугышканда калкан артына үзен ничек  яшерә, саклана - шуның шикелле, ураза да кешене бер тамчы ризыктан, бер тамчы судан гына түгел, ә барча начар уй-фикерләрдән, начар эшләрдән саклый. Рамазан аенда без бөтен көчебезне куеп, шушы уразабызга кимчелек китермичә, җаныбызны да, тәнебезне дә саклыйбыз, аерма юк.

**- Сәхәр тәмамлану иртәнге намазга ничек бәйле? Намазга кадәр ярты сәгать яки 45 минут алдан тәмамларга диген төрле фикерләр бар, кайсы дөрес булыр?**

- Безнең график бар, алар һәрбер мәчеттә бар; күп кенә газеталарда да бирелә. Элегрәк, чыннан да, кояш чыкканчы ярты сәгать алдан, 45 минут алдан сәхәрне тәмамларга кирәк, дигән фикерләр бар иде. Хәзер безнең Диния нәзарәте яңа график эшләп чыгарды, әлхәмдүлилләһ, галимнәр утырып, карап, хәзерге вакыттагы бөтен яссылыкларга күз салып, тәгаенләп, намаз вакытларын һәм сәхәр, ифтар вакытларын билгеләделәр. Намаз уку графикларында сәхәр тәмам дип аерым бер вакыт куела, шул вакытка без сәхәрне тәмамларга тиеш. Догасын кылып, ниятләп уразага керергә тиешбез. Шушы сәхәр тәмам дигән вакыттан соң 5-10 минут үткәч, иртәнге намазның вакыты керә башлый. Графикта иртәнге намазның  мәчетләрдә укыла торган вакыты да күрсәтелгән. Безгә иң мөһиме шул: рамазан аена бирелгән графикта иртән сәхәр тәмам дигән вакыт бар, менә шушы вакытка тикле без ашауны тәмамлап, дога кылып куярга тиешбез. Шул вакытта, иншаллаһ, сәхәребез дөрес булыр.

**- Авыз ачканда ни өчен су, тоз, финик җимешләренә өстенлек бирелә?**

- Су һәм финик, хөрмә җимеше белән авыз ачу пәйгамбәребез (с.г.в.)нең сөннәте булып санала, пәйгамбәребез (с.г.в.) су белән яки хөрмә җимеше белән авыз ача торган булган. Безнең халыкта, татарларда шулай ук тоз белән дә ачу бар, ул безнең гореф-гадәтебез, бу да дөрес була. Шуларга өстенлек бирсәк, хәерле булыр, иншаллаһ; пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтен тоткан булабыз,  әҗере дә күбрәк була. Әлбәттә, бу башка төрле ризык белән авыз ачарга ярамый дигән сүз түгел.

**- Уразаны сәбәпсез калдырган өчен ничек түләргә?**

- Уразаны сәбәпсез калдырырга ярамый. Уразаның көннәре билгеле. Аның турында Коръәндә дә әйтелә, уразаның көннәре санаулы: ул 29 көннән я 30 көннән килә. Мөселман кешесе әгәр дә чирләп китмәсә, сәфәр чыкмаса, башка төрле җитди бер сәбәп булмаса, уразаны калдырырга тиеш түгел. Әгәр дә бер сәбәпсез уразаны калдыра икән, ул вакытта кәффарәт уразасы тотарга тиеш була. Калдырган көн өчен дә тота, аннан, уразадан соң, бер көн өчен 60 көн кәффарәт уразасы тотарга тиеш була. Шәригать китапларында колны азат итү турында да әйтелә. Бүген инде бездә коллар юк. Димәк, 60 көн ураза тота. Ураза тотарлык хәлдә булмаса, 60 кешене ашата, яки 60 көн буе бер кешене ашата – монысы ураза тота алмаган хәлсез кешеләр өчен. Уразаны калдырудан сакланырга кирәк. Әгәр кеше берәр җитди сәбәп белән калдыра икән, аның өчен бер көн генә тотарга тиеш була. Әгәр кеше ялгышып, онытылып ашаса,  ризык капса, капкан ризыгын йоткан булса да, аннан соң шунда ук ашауны туктатса, уразасын дәвам итә, аның уразасы бозылмый. Әгәр кояш баткан дип ялгышып ашаса, ул көнне дә тота һәм соңыннан ул көн өчен бер көн тотарга тиеш була.

*Әңгәмәне* **Нияз ГАЗИЗОВ, Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА** *әзерләде*

## УРАЗАНЫҢ НИЯТЕ

Ураза тотуның төп шартларыннан берсе - ниятләү. Кичтән алып таң атканчыга тикле  теләсә кайсы вакытта ураза тотар өчен ният итәргә була. Әмма иң яхшы вакыт - сәхәр ашаганнан соң. Фәкать, әгәр кеше сәхәргә уянмаса, йокысыннан соңрак торса, ул имсак вакытыннан соң да (иртәнге сәхәрнең тәмам булган вакыты) ният итә ала, кояш инде чыккан булса да. Ләкин көн уртасына тикле ният итеп өлгерергә кирәк. Сәхәргә торырга җыенмаган кеше иртәгесе көн ураза тотар өчен кичтән үк ният итә ала.

## УРАЗАНЫ БОЗМЫЙ ТОРГАН ХӘЛЛӘР

Оныткanлык белән ашау-эчү (җенси якынлык кылу). Әгәр кеше үзенең ураза тотканлыгын исенә төшерү белән ашау-эчүне туктатып, авызына капкан ризыкны чайкап чыгарса, уразасы дәвам итә. Әгәр ураза тотканын исенә төшергәннән соң капкан ризыгын йотып җибәрергә өлгерсә, уразасы бозыла. Түбәндәге хәлләр уразаны бозмый: колакка су элэгү; күзгә дару тамызу; ураза тоткан вакытта су коену; үзең махсус косарга теләмәгәндә косып җибәрү; йоклаганда үзлегеннән мәни чыгу; кан бирү; ялгыш кына тамакка тузан яки төтен элэгү; төкерекне йоту.

*(“Ислам дине нигезләре”ннән)*

## *БЕЛӘСЕЗМЕ?*

Рамазан аенда ураза тотучы кешене ашату да бик изге вә әҗер-саваплы гамәл булып санала. «Кем дә кем ураза тотучыны авыз ачтырса, яки ифтар мәҗлесе оештырса, ураза тоткан кешеләрнең савабы ул кешегә дә языла, әмма ураза тотучының савабы һич тә кимемәс», - диелә хәдистә.

Рамазан ае - ул җәһәннәмнән котылу ае. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу турыда болай дигән: «Рамазан аеның иң беренче кичәсе җитсә, шайтаннар һәм җеннәрнең иң начарлары богаулап куелалар. Бу айда җәһәннәм ишекләре ябыла һәм аның бер ишеге дә ачылмый, шулай ук анда җәннәт ишекләре ачыла һәм аның бер ишеге дә ябылмый. Ул айда бер фәрештә: «Әй изгелек кылырга теләүче! Күбрәк изгелек кыл! Әй гөнаһлар кылырга теләүче! Гөнаһлар кылудан тукта!» - диде».

Рамазан аенда бирелгән сәдаканың әҗер-савабы күбрәк. Әнәс ибн Мәлик әйтә: «Бер вакытны Пәйгамбәребез с.г.в.нән: «Рамазаннан соң кайсы айда ураза тоту хәерлерәк?» - дип сорадылар. Ул: «Рамазанны зурлау өчен Шәгъбән аенда тотылган ураза», - дип җавап бирде. Шуннан соң: «Кайсы сәдака саваплырак?» - дип сорадылар. Ул: «Рамазан аенда бирелгән сәдака», - дип әйтте. Шуңа күрә мөселман кешесе бу айда мохтаҗ кешеләргә күбрәк сәдака бирергә һәм юмартлык күрсәтергә тиеш.

Гомер буе адәм баласының нәфесе белән аңы көрәшә. Без үзебезнең нәфес артыннан кууыбыз белән түбәнгә тәгәрибез. Ә менә Рамазан ае нәфесебездән өстен икәнебезне, аны җиңә алуыбызны күрсәтергә мөмкинлек бирә. Пәйгамбәребез с.г.в.: «Безнең һәркайсыбызның нәфесе бар, әгәр без шушы нәфесебезне җиңсәк, олы җиһадта җиңүчеләр булырбыз», - диде.

# РАМАЗАН - САФЛАНУ АЕ

Бөтен галәмнәргә рәхмәт, мәрхәмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Бер адәм Рамазан аен шатланып каршы алса, һәм Рамазан аеның үтеп китүенә күңеле белән яхшы айлар үтте дип кайгырса, ул адәмгә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт важиб (тиешле) булыр», — дигән. Икенче хәдис-шәрифтә әйтелгән: «Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе Рамазан ае булуны теләрләр иде» (имам Табарани, Бәйһәкый).

Рамазан — барлык гөнаһлардан пакьлану, күңелләрне сафландыру, күркәм сыйфатлар белән бизәкләү ае. Рамазан фазыйләтенә багышланган бер хәдистә Рәсүлаллаһ галәйһиссәләм болай дип әйткән: «Өммәтем гади айда кылган бер яхшы гамәл өчен бер савап ала, әмма Рамазанда исә Аллаһ бер яхшы гамәл өчен җиде йөзгә хәтле һәм аннан да күбрәк әҗер бирә. Фарыз гыйбадәтләренең берсе өчен башка айларда кылган җитмеш фарызның савабын, нәфелләре өчен исә башка айларда кылган фарызның савабын бирә», — дигән.

*(Нияз хәзрәт САБИРОВ вәгазеннән)*

# Рамазан аена намаз вакытлары

| Милади апрель, май | Көн исеме | Рамазан | Иртәнге намаз | | | | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сәхәр тәмам | | | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 13 | Сш | 1 | 04:18 | 02:02 | 02:15 | 04:50 | 03:00 | 03:13 | 06:18 | 04:30 | 04:43 | 13:17 | 11:30 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:01 | 16:16 | 16:29 | 20:16 | 18:32 | 18:45 | 21:46 | 20:30 | 20:44 |
| 14 | Чш | 2 | 04:16 | 01:58 | 02:11 | 04:48 | 02:57 | 03:10 | 06:16 | 04:27 | 04:40 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:03 | 16:17 | 16:30 | 20:18 | 18:34 | 18:47 | 21:48 | 20:33 | 20:47 |
| 15 | Пж | 3 | 04:14 | 01:54 | 02:07 | 04:46 | 02:55 | 03:08 | 06:14 | 04:25 | 04:38 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:04 | 16:19 | 16:32 | 20:20 | 18:36 | 18:49 | 21:50 | 20:36 | 20:50 |
| 16 | Жм | 4 | 04:11 | 01:50 | 02:02 | 04:43 | 02:52 | 03:05 | 06:11 | 04:22 | 04:35 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:05 | 16:20 | 16:33 | 20:22 | 18:38 | 18:52 | 21:52 | 20:39 | 20:53 |
| 17 | Шм | 5 | 04:09 | 01:45 | 01:58 | 04:41 | 02:50 | 03:03 | 06:09 | 04:20 | 04:33 | 13:16 | 11:29 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:07 | 16:21 | 16:34 | 20:24 | 18:40 | 18:54 | 21:54 | 20:42 | 20:56 |
| 18 | Як | 6 | 04:06 | 01:41 | 01:54 | 04:38 | 02:47 | 03:00 | 06:06 | 04:17 | 04:30 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:08 | 16:23 | 16:36 | 20:26 | 18:42 | 18:56 | 21:56 | 20:46 | 20:59 |
| 19 | Дш | 7 | 04:04 | 01:37 | 01:49 | 04:36 | 02:45 | 02:58 | 06:04 | 04:15 | 04:28 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:09 | 16:24 | 16:37 | 20:28 | 18:44 | 18:58 | 21:58 | 20:49 | 21:02 |
| 20 | Сш | 8 | 04:02 | 01:32 | 01:45 | 04:34 | 02:43 | 02:56 | 06:02 | 04:13 | 04:26 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:10 | 16:25 | 16:38 | 20:29 | 18:46 | 19:00 | 21:59 | 20:52 | 21:06 |
| 21 | Чш | 9 | 03:59 | 01:27 | 01:40 | 04:31 | 02:40 | 02:53 | 05:59 | 04:10 | 04:23 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:12 | 16:27 | 16:40 | 20:31 | 18:48 | 19:02 | 22:01 | 20:56 | 21:09 |
| 22 | Пж | 10 | 03:57 | 01:23 | 01:35 | 04:29 | 02:38 | 02:51 | 05:57 | 04:08 | 04:21 | 13:15 | 11:28 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:13 | 16:28 | 16:41 | 20:33 | 18:50 | 19:04 | 22:03 | 20:59 | 21:12 |
| 23 | Жм | 11 | 03:55 | 01:18 | 01:30 | 04:27 | 02:35 | 02:48 | 05:55 | 04:05 | 04:18 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:14 | 16:29 | 16:42 | 20:35 | 18:52 | 19:06 | 22:05 | 21:02 | 21:16 |
| 24 | Шм | 12 | 03:52 | 01:13 | 01:25 | 04:24 | 02:33 | 02:46 | 05:52 | 04:03 | 04:16 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:15 | 16:30 | 16:44 | 20:37 | 18:54 | 19:08 | 22:07 | 21:06 | 21:19 |
| 25 | Як | 13 | 03:50 | 01:07 | 01:20 | 04:22 | 02:31 | 02:44 | 05:50 | 04:01 | 04:14 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:17 | 16:32 | 16:45 | 20:39 | 18:56 | 19:10 | 22:09 | 21:10 | 21:23 |
| 26 | Дш | 14 | 03:48 | 01:02 | 01:14 | 04:20 | 02:28 | 02:41 | 05:48 | 03:58 | 04:11 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:18 | 16:33 | 16:46 | 20:41 | 18:58 | 19:12 | 22:11 | 21:13 | 21:27 |
| 27 | Сш | 15 | 03:46 | 00:56 | 01:09 | 04:18 | 02:26 | 02:39 | 05:46 | 03:56 | 04:09 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:19 | 16:34 | 16:47 | 20:43 | 19:00 | 19:14 | 22:13 | 21:17 | 21:31 |
| 28 | Чш | 16 | 03:43 | 00:50 | 01:03 | 04:15 | 02:24 | 02:37 | 05:43 | 03:54 | 04:07 | 13:14 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:20 | 16:36 | 16:49 | 20:45 | 19:02 | 19:16 | 22:15 | 21:21 | 21:34 |
| 29 | Пж | 17 | 03:41 | 00:44 | 00:56 | 04:13 | 02:21 | 02:34 | 05:41 | 03:51 | 04:04 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:21 | 16:37 | 16:50 | 20:47 | 19:04 | 19:18 | 22:17 | 21:25 | 21:38 |
| 30 | Жм | 18 | 03:39 | 00:37 | 00:49 | 04:11 | 02:19 | 02:32 | 05:39 | 03:49 | 04:02 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:22 | 16:38 | 16:51 | 20:49 | 19:06 | 19:20 | 22:19 | 21:29 | 21:42 |
| 1 | Шм | 19 | 03:37 | 00:30 | 00:42 | 04:09 | 02:17 | 02:30 | 05:37 | 03:47 | 04:00 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:24 | 16:39 | 16:52 | 20:51 | 19:08 | 19:22 | 22:21 | 21:33 | 21:47 |
| 2 | Як | 20 | 03:35 | 00:21 | 00:33 | 04:07 | 02:15 | 02:28 | 05:35 | 03:45 | 03:58 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:25 | 16:40 | 16:54 | 20:52 | 19:10 | 19:24 | 22:22 | 21:37 | 21:51 |
| 3 | Дш | 21 | 03:33 | 00:11 | 00:23 | 04:05 | 02:12 | 02:25 | 05:33 | 03:42 | 03:55 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:26 | 16:42 | 16:55 | 20:54 | 19:12 | 19:26 | 22:24 | 21:41 | 21:55 |
| 4 | Сш | 22 | 03:31 | 23:59 | 00:10 | 04:03 | 02:10 | 02:23 | 05:31 | 03:40 | 03:53 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:27 | 16:43 | 16:56 | 20:56 | 19:14 | 19:28 | 22:26 | 21:46 | 22:00 |
| 5 | Чш | 23 | 03:29 | 23:39 | 23:44 | 04:01 | 02:08 | 02:21 | 05:29 | 03:38 | 03:51 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:28 | 16:44 | 16:57 | 20:58 | 19:16 | 19:30 | 22:28 | 20:46 | 21:00 |
| 6 | Пж | 24 | 03:27 | 01:36 | 01:49 | 03:59 | 02:06 | 02:19 | 05:27 | 03:36 | 03:49 | 13:13 | 11:27 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:29 | 16:45 | 16:58 | 21:00 | 19:18 | 19:32 | 22:30 | 20:48 | 21:02 |
| 7 | Жм | 25 | 03:25 | 01:34 | 01:47 | 03:57 | 02:04 | 02:17 | 05:25 | 03:34 | 03:47 | 13:13 | 11:26 | 11:40 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:30 | 16:46 | 16:59 | 21:02 | 19:20 | 19:34 | 22:32 | 20:50 | 21:04 |
| 8 | Шм | 26 | 03:23 | 01:32 | 01:45 | 03:55 | 02:02 | 02:15 | 05:23 | 03:32 | 03:45 | 13:13 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:32 | 16:47 | 17:01 | 21:04 | 19:22 | 19:36 | 22:34 | 20:52 | 21:06 |
| 9 | Як | 27 | 03:21 | 01:30 | 01:43 | 03:53 | 02:00 | 02:13 | 05:21 | 03:30 | 03:43 | 13:13 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:33 | 16:49 | 17:02 | 21:05 | 19:24 | 19:37 | 22:35 | 20:54 | 21:07 |
| 10 | Дш | 28 | 03:19 | 01:28 | 01:41 | 03:51 | 01:58 | 02:11 | 05:19 | 03:28 | 03:41 | 13:13 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:34 | 16:50 | 17:03 | 21:07 | 19:26 | 19:39 | 22:37 | 20:56 | 21:09 |
| 11 | Сш | 29 | 03:17 | 01:26 | 01:39 | 03:49 | 01:56 | 02:09 | 05:17 | 03:26 | 03:39 | 13:13 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:35 | 16:51 | 17:04 | 21:09 | 19:28 | 19:41 | 22:39 | 20:58 | 21:11 |
| 12 | Чш | 30 | 03:15 | 01:24 | 01:37 | 03:47 | 01:54 | 02:07 | 05:15 | 03:24 | 03:37 | 13:12 | 11:26 | 11:39 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:36 | 16:52 | 17:05 | 21:11 | 19:30 | 19:43 | 22:41 | 21:00 | 21:13 |

***Балалар өчен***

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Тәсбихын минем әбием
Хөрмә төшеннән тезгән.
Истәлек, ди, пәйгамбәрнең (с.г.в.)
Эзләре калган җирдән.



Шул төшләрне саный-саный,
Аллаһны зекер итә,
Безгә бәхет-тәүфыйк тели,
Тормышка шөкер итә.

## СӘХӘР ҺӘМ ИФТАРДА УКЫЛЫРГА ТИЕШ ДОГАЛАР



Сәхәр ашап бетереп, фарыз уразаны тоту өчен ният кылына: ***"Нәвәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәл-фәҗри иләл-мәгърибии хаалисан лилләәһи тәгааләә".***

Мәгънәсе:"Иләһи ният кылдым, Раббым, Үзеңнең ризалыгың өчен Рамазан уразасын тотмакка, таң беленгәннән алып кояш баеганга кадәр".

Кояш баегач исә бер чеметем тоз, су, финик кебек татлы җимешләр белән авыз ачыла һәм түбәндәге дога укыла:

***"Аллаһүммә ләкә сумтү вә бикә әмәнтү вә галәйкә тәвәккәлтү вә галәә ризкыйкә әфтарту фәгъфирлии йә гаффәәрү мәә каддәмтү вә мәә әххартү".***

Мәгънәсе: "Йә Раббым, шушы уразамны мин Синең өчен тоттым һәм мин Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Тоткан уразаларымны кабул кыл, Үзеңнең биргән нигъмәтләрең белән авыз ачам, йә гөнаһларны гафу итүче Аллаһ, минем элек кылган гөнаһларымны да соңгыларын да ярлыка".

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселман-нары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юлларга кирәк.**
**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы соравлары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 24 март 16 сәг.**
**фактта 24 март 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**